ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.11.2021 с.Старое Дрожжаное №463

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 21 июнендәге 334 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы карары белән расланган, «Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 29 октябрендәге 1021 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 21 июнендәге 334 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында Нигезләмәгә, «мәгариф программасы үзенчәлеге өчен өстәмәләр күләме» 2 нче таблицаның 1,2 пунктларын, үзгәреш кертеп, түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Авыл җирендә һәм шәһәр тибындагы поселокларда урнашкан рус теле булмаган белем бирү оешмаларында балаларны рус теленә өйрәтү | Педагогик хезмәткәр вазифалары | өченче – дүртенче | 5,0 |
| 2. | Рус телле мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында балаларга туган телне (татар, чуаш, мари һ.б.) рус теленнән тыш) укыту | Педагогик хезмәткәр вазифалары | өченче – дүртенче | 5,0». |

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2021 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе: Д.А. Сатдинов